**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОКАДЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Советская ул, 51, с.Утыз Имян, 423109

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 51, Утыз Имән
авылы,423109

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

**№123** **23 август 2024 ел**

**РЕШЕНИЕ КАРАР**

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2019 елның 7 февралендәге 96 номерлы
Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль
районының Яңа Кади авыл җирлеге Советы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын, салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның 2024 елның 05 июнендәге 26981-МР номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Кади авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 7 февралендәге 96 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Кади авыл җирлеге Советы карарына (Советның 10.06.2019 №108, 30.09.2021 №38 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 4 пунктчасының 1 абзацында: «2015 елда - 1,2 процент, 2016 елда - 1,5 процент, 2017 елда – 1,8 процент, 2018 елда һәм аннан соңгы елларда – 2 процент» сүзләрен түбәндәге эчтәлекле сүзләргә алмаштырырга «2025-2027 еллар чорына түбәндәгеләргә карата 1,2 процент: административ-эшлекле үзәкләргә һәм гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм андагы биналарга».
- 2 пунктның 4 пунктчасындагы 2 абзацта: «салым салу объектларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Кади авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе М.М.Әминов